| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА БУРМЕТЬЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>НУРЛАТСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КИЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Киекле ав. **КАРАР**

«16» октябрь 2023 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Кизләү авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ**:

1. 2023 елның 7 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Кизләү авылы, Клуб урамы, 3нче йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Кизләү авылында Клубная, Мира, Прибрежная, Привольная, Тимуровская, А. Халиков урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2023 елның 7 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Кизләү авылы, Животноводская урамы, 29нчы йорт адресы буенча урнашкан йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Кизләү авылында Животноводская, Мостовая урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3.. 2023 елның 7 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Кизләү авылы, Спортивная урамы, 19нчы йорт адресы буенча урнашкан йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Кизләү авылында Интернациональная, Огородная, Спортивная, Черемшанская, Шоссейная урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. 2023 елның 7 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка Кизләү авылы, Клубная урамы, 3нче йорт адресы буенча урнашкан йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Кизләү авылында Татарстанская, Октябрьская, Пионерская, Почтовая, Школьная, Октябрьско-Пионерская. Переулок Почтовый урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

2. Кизләү авылында яшәүче гражданнар өчен гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

«Киекле авыл җирлегенең Кизләү авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнарның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, СВО зонасында катнашучылардан кала, балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм эчәр су белән тәэмин итү максатыннан халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- Кизләү авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту, таш, ватылган кирпеч, грунт, вак таш, ком, кулланылган асфальт җәю (сатып алу, ташу, җәю), чокырларны ремонтлау (юеш коелган асфальт);

- Кизләү авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен эшләр һәм хезмәтләр, товарлар сатып алу;

-Кизләү торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;

- ремонт, коймалар тоту, Кизләү торак пунктында ураншкан ике зират тирәсен төзекләндерү;

халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, спорт мәйданчыклары, балалар мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау, товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кизләү авылының мәгълүмат стендларында халык җыены үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Киекле авыл җирлеге башлыгы Л.И. Кашапова